# Эдуард Касыймовның тууына 60 ел



## Күңелдә моңсулык, йөрәктә югалту хисе...

"Гомер ике килми"... Әйе шул, ике килми... Моны бигрәк тә талантлы кеше дөньядан киткәндә аңлыйсың икән. Күренекле каләмдәшебез, мөхтәрәм укытучыбыз, дустыбыз Эдуард абый Касыймов иҗат кешесе өчен әле япь-яшь, илле алтынчы яшендә генә бу дөньядан китеп барды. Аның әдәбият гөлстанында, һичшиксез, чәчәк аткан чагы иде. Руслар "от сумы и от смерти не отрекаются" – диләр. Дөрес түгел! Язучы җаны өчен үлем юк ул. Менә бит, Эдуард абыйның да (үзе инде безнең арада яшәмәсә дә) китап арты китабы чыгып тора: КАМАЗ яшьләре турында "Шиңмәсен гөлләрең" исемле романы 1986 елны, ә "Гомер ике килми" исемле сайланма әсәрләр җыентыгы быел укучыларны сөендерде.

Эдуард Салихҗановичның инде дөнья күргән егермедән артык ки-

ятыбызның зур остазлары – Василий Белов, Шәйхи Маннур, Рафаил Төхвәтуллиннар рәтенә куйды.

Эдуард Салихҗан улы Касыймов 1930 елның 8 ноябрендә Киров өлкәсендәге Нократ авылында туа. Җиде яше тулып сигезенчегә киткәндә үк атасыз калып, "халык дошманы улы" дигән ярлык йөртергә туры килүгә карамастан, зур нужалар кичеп, Эдуард Салихҗанович урта белем алуга ирешә һәм Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә керә. Ул университетны 1953 елны кызыл диплом белән тәмамлап, Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының

ранты булу дәрәҗәсенә ирешкәнче Азнакай районында, Киров өлкәсендә укытучы булып эшли. Шул ук вакытта ул халык авыз иҗатын һәм халык тормышын өйрәнә.

Фән эшлеклесе, фольклорист Э.Касыймов 1966 елны "Татар халык әкиятләрендә сатира һәм юмор" темасына филология фәннәре кандидаты дәрәҗәсенә диссертация яклый. Шул ук елларда берничә фольклор җыентыклары чыгара.

Илленче-алтмышынчы елларда аның матур әдәбият әсәрләре дә республика матбугатында еш кына күренгәли һәм укучылар игътибарын үзенә тарта башлый. Мөгаен, нәкъ шул елларда Эдуард

лендә фольклорчыны булачак язучы җиңә, һәм дә ул "кендеген" язучы өстәленә ныклап бәйләп куя.

Ниһаять, алтмышынчы елларда дөнья күргән "Кояш көн дә чыга" исемле повесте, бигрәк тә "Гомер ике килми" романы укучыларда һәм тәнкыйтьчеләрдә зур кызыксыну уята. Хәтта соңгы елларда аның бу романын кайбер тәнкыйтьчеләр язучының иң яхшы әсәре дип тә таный башладылар. Бәлки шулайдыр.

1978 елда "Чулман – оныклар дәрьясы" исеме астында Мәскәүдә басылып чыккан һәм эшчеләр темасына язылган әсәре профсоюз һәм СССР Язучылар союзының кызыксындыру премиясенә лаек булды. Эдуард Касыймов әсәрләре Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә дә тәкъдим ителгән иде. Әдәбият өлкәсендәге уңышлары өчен ул "Почет билгесе" орденына һәм медальләргә лаек булды.

Гомер ике килми... Язучылар бу дөньядан киткәндә әсәр-әсәр булып аларның күңел җылысы кала, изге ниятләре, кылган эшләре кала. Әмма бүген күңелдә моңсулык, йөрәктә югалту хисе... Әгәр дә 1986 елның 21 мартында Эдуард абый фаҗигале рәвештә безнең арадан китмәгән булса, аңа 60 яшь тулыр иде. Әле 60 яшь кенә!..

Үзебез төзегән калабыздагы Касыймов бульвары буенча акрын гына уйланып барам. Ап-ак кар бөртекләре назлы гына итеп җиргә төшә, мөхтәрәм укытучыбыз турындагы хатирәләрне яңарта кебек.

Мансур САФИН,
Эдуард Касыймов пре-